# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1** **28 октябрь 2022 ел**

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге составына керүче
Әлкәй авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә 2022 елның 28 октябрендәге түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләрдән тыш, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (Әлкәй авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар декасы», «Яңа ел» бәйрәмнәрен үткәрүгә бүләк һәм сувенир продукциясен сатып алу);
- Әлкәй авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен түләү, чит оешмаларның юлларны кардан чистарту хезмәтләре);
- территорияне төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырылган чаптыру хезмәтләре өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, Әлкәй авылы территориясен яшелләндерү чаралары);
- җирлектә яшәүчеләр өчен массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру (Әлкәй авылында парк төзекләндерү);
- халыкны су белән тәэмин итү (эчә торган су линияләрен һәм колонкаларын ремонтлау).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 309 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 177.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 177, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (Әлкәй авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар декасы», «Яңа ел» бәйрәмнәрен үткәрүгә бүләк һәм сувенир продукциясен сатып алу);
- Әлкәй авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен түләү, чит оешмаларның юлларны кардан чистарту хезмәтләре);

- территорияне төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырылган чаптыру хезмәтләре өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, Әлкәй авылы территориясен яшелләндерү чаралары);

-җирлектә яшәүчеләр өчен массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итэ торган урыннарны төзекләндерүне оештыру (Әлкәй авылында парк төзекләндерү);

-халыкны су белән тәэмин итү (эчә торган су линияләрен һәм колонкаларын ремонтлау).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге башлыгы С.З.Зиннурова